ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 604 31 июль,2018

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августында кабул ителгән 553 нче карары, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Расларга :

1) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне, 1нче кушымта нигезендә;
2) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга хокук бирүче электрон аукционны үткәрү һәм оештыру нигезләмәсен, 2нче кушымта нигезендә.

2. Вәкаләтле орган итеп билгеләргә:

1) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга хокук бирүче электрон аукционны үткәрү һәм оештыру буенча Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль заказ урнаштыру бүлеген;
2) стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга хокук бирүдә килешүләр төзү эшен оештыру буенча һәм аларны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе» казна учреждениесен.

3. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән эш бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.И.Беляевка йөкләргә.

А.Г. Сәйфетдинов